| | |
|---|---|
| «Кабул ителде»<br>Педсовет утырышы беркетмәсе №<br>август 2021-2022 ел<br>" 2 нче санлы "Теремкәй" балалар<br>бакчасы"мөдире ______ /К.Г.Бахтиярова/ | "Расланды"<br>№ боерык белән гамәлгә кертелде<br>август 2021-2022 ел<br>" 2 нче санлы "Теремкәй" балалар<br>бакчасы"мөдире ______ /К.Г.Бахтиярова/ |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы

" 2 нче санлы "Теремкәй" балалар бакчасы"

мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе

татар теле тәрбиячесе Гараева Ләйсән Миннур кызының

эш программасы ***"Татарча сөйләшәбез"***

# Аңлатма язуы

***Эш программасы статусы.***

Программа “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасына, Федераль дәүләт таләпләренә нигезләнеп төзелде. Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләренең эчтәлеген чагылдыра. Программа балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган: телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.

Татар теленә өйрәтү уртанчылар төркемендә атнасына 2 тапкыр режим вакытларында, зурлар төркемендә 2 тапкыр эшчәнлек, ә мәктәпкә әзерлек төркендә 2 тапкыр эшчәнлек, 1 тапкыр  режим вакытларында уздырыла.

***Эш программасы структурасы*.**

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтү буенча эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуы,төп өлеш (тематик план), мониторинг, өстәмә өлеш (лексик минимум, дидактик уенар, милли региональ компонент).

***Эш программасының эчтәлеге*.**

**Татарча сөйләшергә өйрәткәндә куелган минимум бурычлар.**

Программа өч проектны һәм аларның  төп максатларын һәм бурычларын үз эченә ала:

**“Минем өем” проекты (4-5 яшь).**

Максат: Татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.

Бурычлар:

1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.
2. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.
3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты (5-6 яшь).**

Максат: Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

Бурычлар:

1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты (6-7 яшь).**

Максат: Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

Бурычлар:

1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

## Укыту методик комплект.

1. Программа “ Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы” Р.КШаехова.
2. Методик кулланма. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә өйрәтү эшчәнлеген планнаштыру. Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. Казан. Хәтер. 2018.
3.Эш дәфтәре 4-5 яшь “Татарча сөйләшәбез”
4.Татарча сөйләшәбез “Минем өем” Аудиоязма.Т.Р. мәгариф һәм фән министрлыгы.Компания”Аксу” 2011.
5.Күрсәтмә әсбаплар” Татарча сөйләшәбез”.Казань. Татарское книжное издательство,2012.
6. Татарча сөйләшәбез. Эш дәфтәре 5-6 яшь.
7.Күрсәтмә һәм таратма материаллар. “ Уйный- уйный үсәбез” 5-6 яшь. Казань. Татарское книжное издательство,2012
8. Татар теле укыту буенча УМК аудиоязмалары. Татарча сөйләшәбез. 5-6 яшь. Т.Р. мәгариф һәм фән министрлыгы.Компания”Аксу” 2011
9. Татарча сөйләшәбез. Эш дәфтәре 6-7 яшь.
10. Күрсәтмә һәм таратма материаллар. “ Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”6-7 яшь.
11. Татар теле укыту буенча УМК аудиоязмалары. Татарча сөйләшәбез. 6-7 яшь.
12.”Раз словечко два словечко”.Занимательное обучение татарскому языку. Р.К.Шаехова.Казань.Хәтер.2011.
13.На поляне детства. Хрестоматия для воспитателей дошкольных образовательных учреждений и родителей. Министерство образования и науки Р.Т. Казань.2011.
14. Балачак аланы. Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия. Казан. Риц нәшрияты 2011.
15.Балачак – уйнап көлеп үсәр чак. Методик кулланма.Т.Р. мәгариф һәм фән министрлыгы.Казан.2012.

# Тематик планлаштыру

## “Минем өем” проекты. (4-5яшьлек балалар өчен)

| № | Проект темалары | Сәгать | Эшчәнлек темалары |
|---|---|---|---|
| 1 | Гаилә | 12 | 1.Минем гаиләм.2.Малай,кыз.3.Минем туганнарым.4-5.Әйдәгез, танышыйк . 6.Тату гаилә.7-8Минем дуслар .9 Әйдәгез, дуслашыйк. 10-11.Әйе-юк..12Качышлы уйныйбыз.Мультфильм карау.13-14.Кунак килгән.15.Әйдәгез, уйныйбыз.16-17.Безнең кунаклар.18.Шалкан әкияте. Мультфильм карау. |
| 2 | Ашамлыклар | 9 | 1.Әби күчтәнәче.2.Бабай күчтәнәче.3.Безнең кунаклар.Мультфильм карау.4.Сөт,чәй.5.Дустыңны сыйла.6.Рәхмәт әйт.7.Песине сыйла.8.Кунак сыйла.9.Тәмле кибетендә.Мультфильм карау.10.Кунукны ашат.11.Чәй табынында.12.Азат кунак чакыра.Мультфильм карау. |
| 3 | Уенчыклар | 23 | 1.Уенчыклар.2.Зур- кечкенә.3.Күңел ачу кичәсе – “Туган көн”4.Курчак кунакка килгән.5.Уенчыклар кибете.6.Паркка сәяхәт. Мультфильм карау.7.Яңа уенчыклар.8.Уйныйбыз.9.Без уйнарга яратабыз.10.Мияга- бүләк”.11.Уенчыклар кибете.12.Уенчыклар үпкәләгән. Мультфильм карау.13.Бүләкләр.14. Уйна.15.Күңелле уеннар.Мультфильм карау16. Уенчыклар юабыз.17.Ю.18.”Акбай һәм Мияу маҗаралары.”Мультфильм карау. |
| 4 | Саннар | 6 | 1.Саннар.(2).3. Уйныйбыз да саныйбыз.4.Уенчыклар.5.Ничә уенчык.6.”Уйный-уйный саныйбыз.”Мультфильм карау. |
| 5 | Кабатлау. | 15 | 1.Бергәләп уйныйбыз.2.Кунак чакырабыз.3.Күңелле ял итәбез.4.Без татарча сөйләшәбез.5.Бу өйдә кем яши.6.Без театр уйныйбыз. |

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты. (5-6 яшьлек балалар  өчен)**

| № | Проект темалары | Сәг. | Эшчәнлек темалары |
|---|---|---|---|
| 1 | “Минем өем “ проекты буенча кабатлау | 2 | “Минем өем”, “Кем юк? ”,”Шалкан әкияте”. |
| 2 | Яшелчәләр | 18 | “Кишер үстерәбез”,”Куян күчтәнәче”,”Баллы кишер”,”Серле кәрзин”,”Сыйлыйбыз”,”Бар матур бакча”,”Серле янчык”,”Серле кәрзин”,”Бар матур бакча”,Без хезмәт яратабыз”,”Яшелчәләр кибете”,Уйный- уйный эшлибез”,”Төсләр дөньясы”,”Юл маҗаралары”,”Яшелчә салаты”,”Яшелчә ю”,”Кем эшләми, шул ашамый”,”Яшелчәләр кибете”,”Уйныйбыз да , җырлыйбыз да”,”Уңыш бәйрәме”, |
| 3 | Төсләр | 4 | “Төсләр дөньясы», «Төсле туплар”, “Юл маҗаралары”, “Төсләр дөньясы». |
| 4 | Ашамлыклар | 6 | “Ашамлыклар”, “Ашханә”,”Аш бүлмәсе”,”Аю кунакка килгән”,”Кибеттә”,”Кем нәрсә ярата”, |
| 5 | Савыт- саба | 6 | “Туган көн”,”Курчак Алиягә булыш”,”Өч аю”,”Чәй табыны әзерлибез”,”Төсле чынаяклар”,”Чисталыкта матурлык”, |
| 6 | Киемнәр | 8 | “Туган көнгә яңа киемнәр”,”Курчакны киендер”,”Без киенәбез”,”Киенергә ярдәм |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | ит”,”Алия йокларга җыена”,”Шаян уенчыклар”. |
| 7 | Шәхси гигиена | 4 | “Хәерле көн”, “Курчак белән уйныйбыз”,”Ни өчен киемнәр югалган”. |
| 8 | Өй җиһазлары | 3 | Өстәл театры “Өч аю”,”Җиһазлар кибете”,”Маша һәм өч аю”, |
| 9 | Бәйрәм “Туган көн” | 9 | “Уенчыклар иленә сәяхәт”,”Курчакның туган көне”,”Туган көн”,”Уйнарга яратабыз”,”Син нәрсә яратасың?”,”Кем нәрсә ярата?”,”Уйный-уйный үсәбез”,”Нәрсә бар?”,”Бар, юк”. |
| 10 | Бәйрәм  “Сабантуй” | 3 | Сабантуйга әзерләнәбез”, “Күңелле Сабантуй уеннары”,” “Сабантуй “ бәйрәме. |

## “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты.(6-7 яшьлек балалар)

| № | Проект темалары | Сәгать саны | Эшчәнлек темалары |
|---|---|---|---|
| 1 | Кабатлау | 3 | 1.Әйдәгез, танышабыз. 2.Хәерле көн. 3.Мультфильм карау |
| 2 | Әкиятләр илендә | 3 | 1. Син кем? 2. “Шалкан” әкиятен сәхнәләштерү. 3.“Әкият илендә” анимацион сюжет карау. |
| 3 | Яраткан уенчыклар | 13 | 1.Бу нәрсә? 2.Кем нишли? 3.Мультфильм карау.4.Бу нәрсә? 5.Кем нишли? 6.”Әкият илендә”. 7.Дусларны сыйлыйбыз. 8.Нишлисең?9.Тату гаилә. 10. Дусларны сыйлыйбыз. 11.Нишлисең? 12.Кем нишли?13.Әйдәгез, уйныйбыз. |
| 4 | Кунак килде | 5 | 1.Кунак килде. 2.”Әкият илендә”.3.Әйдәгез, уйныйбыз.4.Кунак килде.5.”Әкият илендә”. |
| 5 | Кафега барабыз. | 5 | 1.Кафега барабыз. 2.Без кафеда.3.“Кафега барабыз” мультфильм карау. 4.Без кафеда.5.Кафега барабыз. |
| 6 | Без уйнарга яратабыз. | 10 | 1.Күңелле уеннар.(2) 3. Мультфильм карау.4.Спорт бәйрәменә әзерләнәбез.5.Бәйрәмгә барабыз.6.Көчлеләр,кыюлар,җитезләр. 7.Казанда спорт бәйрәме.(2) 8. Мультфильм. |
| 7 | Циркта. | 12 | 1.Без циркта(2). 2. Җәнлекләр спорт бәйрәмендә. 3.Безнең дуслар. 4.Үрдәк дусларын тапты. 5.Мультфильм карау”Сертотмас үрдәк”.6.Безнең дуслар(4). 7.”Әкият илендә”.Циркта.8. Мультфильм “Чукмар белән Тукмар”. |
| 8 | Кышкы уеннар | 6 | 1.Акбай чана шуа. 2.Чана шуам.3.Тауда(3).4.Шаян кошлар. |
| 9 | Без биергә яратабыз. | 5 | 1.Әйдә, бие! 2.Без биибез (4). 3.Урманда зур концерт. |
| 10 | Бәйрәм. Туган көн. | 9 | 1.Мияуның бүлмәсен бизибез.2.Туган көнгә бүләк әзерлибез. 3.Акбай туган көнгә барырга әзерләнә.4.Туган көнгә әзерләнәбез(3).5.Мияуның туган көне(3). |
| 11 | Без сәяхәтчеләр. | 11 | 1.Күңелле сәяхәт (4). 2. Урман китапханәсендә.3.Уйный-уйный укыйбыз. 4.Мәктәптә.5. Уку бүлмәсе. 6.Урман мәктәбендә. 7. Потфельдә нәрсә бар? 8.Нәрсә кирәк? 9.Нәрсә?Нинди?Ничә? |
| 12 | Өстәл театры | 6 | 1.Өстәл театры “Теремкәй”.2.”Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерү.3.Мультфильм “Теремкәй”.4.Өстәл театры “Кем нәрсә ярата?”5.“Кем нәрсә ярата?” әкиятен сәхнәләштерү. 6. Мультфильм “Кем нәрсә ярата?” |
| 16 | Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар | 6 | 1.Белем иленә сәяхәт. 2.“Могҗизалар кыры” уены. 3. Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар. 4.Татарча сөйләшәбез. 5.Могҗизалар кыры.6. Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар. |

# Диагностика.

Түбәндәге биремнәрне балаларның татар телен белү дәрәҗәсен билгеләгәндә кулланырга мөмкин. Тикшерү һәр бала белән аерым үткәрелә, ул 5 – 10 минуттан артмаска тиеш. Ә йомгаклау дәресе булганда, тикшерүне барлык балалар белән бергә үткәрергә мөмкин. Биремнәр уен формасында рус телендә аңлатыла. Балаларның җавабын тыңлаганда тикшерүче елмаеп, кирәк булса, җавапны дөресләп, бала әйтә алмаган очракта, булышырга тиеш.

Тикшерү нәтиҗәләрен түбәндәгечә таблицага төшерергә мөмкин.

Нәтиҗәгә карап, тәрбияче, һәр бала белән эшләү өчен, бурычлар билгели.

**Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының “Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Балаларның исем, фамилиясе | **Сүз байлыгы** | | **Бәйләнешле сөйләм** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч) | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) |
| 1. | Коля | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | |
| 3. | ..... | | | | | |
| 4. | ..... | | | | | |
| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | | | | | | |

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә<br>2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Балаларның исем, фамилиясе | **Сүз байлыгы** | | **Бәйләнешле сөйләм** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”. “исәнмесез”, “ сау булыгыз”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) |
| 1. | | | | | | |
| 2. | | | | | | |

**Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының**
**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча**
**татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Балаларның исем, фамилиясе | **Сүз байлыгы** | | **Бәйләнешле сөйләм** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “исәнмесез”, “сау бул”, “сау булыгыз”, “рәхмәт”, “зур рәхмәт”, “хәерле көн”, “хәлләр ничек?”, “әйбәт”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, җырла, йөгер, йокла) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау) |
| 1. | Коля | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | |
| 3. | ..... | | | | | |
| 4. | ..... | | | | | |

**Дидактик уеннар**

***«Минем өем» проекты***

| | |
|---|---|
| **Дидактик уен**<br>**“Бу кем? – Это кто?”**<br>*к проекту «Минем өем»*<br>(диалог между воспитателем и детьми т.к. дети 4-5 лет друг-другу вопросы не задают).<br>**Тәрбияче: Бу кем?**<br>**Бала:** Әти.<br>**Тәрбияче: Бу кем?**<br>**Бала:** Әни, (бабай, әби, әти, кыз, малай).<br>**Тәрбияче: Әни нинди?**<br>**Бала:** Әни зур, матур, чиста, әйбәт. | **Дидактик уен**<br>**“Бу нәрсә? – Это что?”** *к проекту «Минем өем»*<br>(диалог между воспитателем и детьми т.к. дети 4-5 лет друг-другу вопросы не задают).<br>**Тәрбияче: Бу нәрсә?**<br>**Бала:**Чәй (сөт, ипи, алма).<br>**Тәрбияче: Сөт нинди?**<br>**Бала:**Сөт тәмле.<br>**Тәрбияче: Бу нәрсә?**<br>**Бала:** Эт (песи, туп, курчак, куян, аю ).<br>**Тәрбияче: Эт нинди?**<br>**Бала:** Эт зур,(кечкенә) матур, әйбәт,чиста, (пычрак). |
| **Дидактик уен**<br>**“Әйе – Юк.”**<br>*к проекту «Минем өем»*<br>(диалог между воспитателем и детьми, между детьми, у детей “маски”). | **Дидактик уен**<br>**“Әйе – Юк.”**<br>*к проекту «Минем өем»*<br>(диалог между воспитателем и детьми, т.к. дети 4-5 лет друг-другу вопросы не задают, у детей |

| | |
|---|---|
| **Тәрбияче:** Әни?<br>**Бала:** Әйе.<br>**Тәрбияче:** Әти?<br>**Бала:** Юк.<br>**Саша:** Малай?<br>**Бала:** Юк.<br>**Маша:** Кыз?<br>**Бала:** Әйе.<br>**Коля:** Песи?<br>**Бала:** Әйе. | "маски")<br>**Тәрбияче:** Син Коля?<br>**Коля:** Әйе. Мин Коля.<br>**Тәрбияче:** Коля, син кыз? (әби,бабай, әти, әни).<br>**Коля:** Юк, мин малай.<br>**Тәрбияче:** Оля, син кыз?<br>**Оля:** Әйе, мин кыз.<br>**Тәрбияче:**Юля, син әби?<br>**Юля:** Әйе, мин әби. |
| **Дидактик уен**<br>**"Кем юк? – Кого нет?"**<br>*к проекту «Минем өем»*<br>(диалог между воспитателем и детьми т.к. дети 4-5 лет друг-другу вопросы не задают).<br>**Тәрбияче:** Кем юк?<br>**Бала:** Әти (әни, кыз, малай).<br>**Тәрбияче:** Кем юк?<br>**Бала:** Әни юк. | **Дидактик уен**<br>**"Нәрсә юк? - Чего нет?"**<br>*к проекту «Минем өем»*<br>(диалог между воспитателем и детьми т.к. дети 4-5 лет друг-другу вопросы не задают).<br>**Тәрбияче:** Нәрсә юк?<br>**Бала:** Эт (песи, туп, курчак, куян, аю).<br>**Тәрбияче:** Нәрсә юк?<br>**Бала:** Эт юк. |
| **Дидактик уен**<br>**"Уйна! – Играй!"**<br>*к проекту «Минем өем»* | **Дидактик уен**<br>**"Бир әле – Дай пожалуйста."**<br>*к проекту «Минем өем»* |

| | |
|---|---|
| (диалог между воспитателем и детьми, между детьми. Дети дарят свои “игрушки” персонажу).<br>**Саша:** Мә, туп уйна!<br>**Маша:** Мә, курчак уйна!<br>**Лена:** Мә, зур песи уйна!<br>**Коля:** Мә, кечкенә аю уйна!<br>**Миша:** Мә, куян уйна!<br>**Даша:** Мә, эт уйна!<br>**Оля:** Мә, машина уйна! | (диалог между воспитателем и детьми. Дети спрашивают “игрушки”, дарят персонажу).<br>**Саша:** Аю *(куян, эт, песи, курчак, машина, туп)* бир әле.<br>**Тәрбияче:** Нинди аю!<br>**Саша:** Зур, матур, чиста, әйбәт аю.<br>**Тәрбияче:**Мә зур, матур, чиста, әйбәт аю. |
| **Дидактик уен**<br>**“Бир әле – Дай пожалуйста.”**<br>*к проекту «Минем өем»*<br>(диалог между воспитателем и детьми т.к. дети 4-5 лет друг-другу вопросы не задают).<br>**Саша:** Алма бир әле.<br>**Тәрбияче:**Нинди алма!<br>**Саша:** Тәмле алма.<br>**Тәрбияче:** Мә тәмле алма.<br>**Саша:** Рәхмәт. | **Дидактик уен**<br>**“ Ничә? – Сколько?”**<br>*к проекту «Минем өем»*<br>(диалог между воспитателем и детьми т.к. дети 4-5 лет друг-другу вопросы не задают).<br>**Тәрбияче:** Ничә алма?<br>**Бала:** Бер (ике, өч, дүрт, биш,) алма.<br>**Тәрбияче:** Мә бер алма.<br>**Бала:** Рәхмәт.<br>**Тәрбияче:** Ничә куян?<br>**Бала:** Биш куян.<br>**Тәрбияче:** Мә биш куян.<br>**Бала:** Рәхмәт. |
| **Дидактик уен** | |

| | |
|---|---|
| **“Ничә? – Сколько?"**<br>*к проекту «Минем өем»*<br>(диалог между воспитателем и детьми, между детьми).<br>**Тәрбияче:** Бер?<br>**Бала:** Әйе, бер.<br>**Тәрбияче:** Өч?<br>**Бала:** Юк, дүрт.<br>**Тәрбияче:** Өч?<br>**Бала:** Юк, дүрт. | |

***«Уйный – уйный үсәбез» проекты***

| | | |
|---|---|---|
| **Дидактик уен**<br>**“Бу нәрсә? Нинди? Ничә? – Это что? Какой? Сколько?”**<br>*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»*<br>(диалог между воспитателем и детьми, между детьми).<br>**Маша:** Бу нәрсә?<br>**Саша:** Бу кишер (суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә,алма).<br>**Маша:** Нинди кишер?<br>**Саша:** Тәмле (баллы), зур (кечкенә), | | **Дидактик уен**<br>**“Бу нәрсә? Нинди? – Это что? Какой?”**<br>*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»*<br>(диалог между воспитателем и детьми, между детьми).<br>**Акбай:** Бу нәрсә?<br>**Мияу:** Бу туп (куян, курчак, машина, аю, эт, песи).<br>**Акбай:** Нинди туп?<br>**Мияу:** Кечкенә (зур) туп (куян, курчак, |

| | | |
|---|---|---|
| чиста (пычрак) кишер.<br>**Маша:** Ничә кишер?<br>**Саша:** Бер ( ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде,сигез, тугыз, ун) кишер. | | машина, аю, эт, песи). |
| **Дидактик уен**<br>**“Бу нәрсә? Нинди? – Это что? Какой?”**<br>*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»*<br>(диалог между воспитателем и детьми, между детьми).<br>**Акбай:** Бу нәрсә?<br>**Оля:** Суган.<br>**Акбай:** Суган нинди?<br>**Оля:** Кечкенә.<br>**б)Мияу:** Бу нәрсә?<br>**Коля:** Бәрәңге.<br>**Мияу:** Бәрәңге нинди?<br>**Коля:** Зур. | | **Дидактик уен**<br>**“Бу нәрсә? Нинди? – Это что? Какой?”**<br>*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»*<br>(диалог между воспитателем и детьми, между детьми).<br>**Маша:** Бу нәрсә?<br>**Саша:**Тәлинкә (чынаяк, кашык).<br>**Маша:** Тәлинкә (чынаяк, кашык) нинди?<br>**Саша:**Тәлинкә (чынаяк, кашык) матур, чиста , кызыл (сары, яшел, зәңгәр). |

**Дидактик уен**
**“Нәрсә кирәк? –Что надо?”**
*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми).

**Малай:** Исәнме, Мияу.
**Кыз:** Исәнме, Акбай.
**Малай:**Нәрсә кирәк?
**Кыз:**Туп кирәк.
**Малай:** Нинди туп?
**Кыз:** Зур (кечкенә, матур, чиста, пычрак, әйбәт) туп.
**Малай:** Мә, зур , матур, чиста, әйбәт туп.
**Кыз:** Рәхмәт. Сау бул, Саша.
**Малай:** Сау бул, Оля.

**Дидактик уен**
**“Нәрсә кирәк? –Что надо?”**
*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми).

**а)** – Коля, нәрсә кирәк?
- Бәрәңге кирәк.
- Мә, бәрәңге.
- Рәхмәт.

**б)** – Оля, нәрсә кирәк?
- Алма кирәк.
- Нинди алма?
- Яшел алма.
- Мә, яшел алма.
- Рәхмәт.

**в)** – Лена, нәрсә кирәк?
- Кәбестә кирәк.
- Ничә кәбестә?
- Дүрт кәбестә.
- Мә, дүрт кәбестә.
- Рәхмәт.

**Дидактик уен**

**“Бир әле – Дай пожалуйста.”**

*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми).

-Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.

-Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?

-Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр) кашык.

-Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?

-(1-10 ) кашык (тәлинкә, чынаяк).

-Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк).

**Дидактик уен**

**“Нәрсә кирәк? –Что надо?”**

*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми).

-Нәрсә кирәк?

-Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.

-Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?

-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).

-Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).

-Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле.

**Дидактик уен**

**“Бир әле – Дай пожалуйста.”**

*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми).

а. -Оля, күлмәк (чалбар) бир.

-Нинди күлмәк (чалбар)?

-Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).

**Дидактик уен**

**“Нәрсә кирәк? –Что надо?”**

*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми).

-Нәрсә кирәк?

-Карават (өстәл, урындык) кирәк.

-Нинди карават?

-Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр)

| | | |
|---|---|---|
| -Ничә күлмәк (чалбар)?<br>-Бер (1-10) күлмәк (чалбар).<br><br>-Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>б.-Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>-Мә, чалбар (күлмәк).<br>-Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br>-Курчак, йокла. | | караватат.<br>-Мә, зур караватат.<br>-Рәхмәт. |
| **Дидактик уен**<br>**“Нәрсә бар? –Что есть?”**<br>*к проекту «Уйный – уйный үсәбез»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми).<br>-Нәрсә бар?<br>-Туп (курчак) бар.<br>-Нәрсә юк?<br>-Туп (курчак) юк.<br>( По образцу повторить темы “Семья”, “Овощи”,“Игрушки”,“Посуда”,”Мебель”, “Одежда”). | | |

***«Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар» проекты***

**Дидактик уен**

**“Нишли? –Что делает?”**

*к проекту «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми).

**Оля:** Коля, куян нишли?

**Коля:** Куян йоклый. Аня, песи нишли?

**Аня:** Песи сөт эчә. Петя, аю нишли?

**Петя:** Аю чана шуа.

**Тәрбияче:** Әни нишли?

**Бала:** Әни кул юа (йоклый).

**Тәрбияче:** Куян нишли?

**Оля:** Куян сикерә. Тычкан нишли?

**Саша:** Тычкан сыр ашый.

**(Ашый, эчә, утыра, басып тора, сикерә, уйный, йөгерә, юа, йоклый, кия, сала, чана шуа, җырлый, бии, китап укый, рәсем ясый).**

**Дидактик уен**

**“Син нишлисең? –Что ты делаешь?”**

*к проекту «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми.

**Коля:** Оля, син нишлисең?

**Оля:** Сөт (чәй) эчәм. Коля, син нишлисең?

**Коля:** Алма (ипи) ашыйм.

Саша, син нишлисең?

**Саша:** Утырам.

**( Ашыйм, эчәм, утырам, басып торам, сикерәм, уйныйм, йөгерәм, юам, киям, салам, йоклыйм, чана шуам, җырлыйм, биим, китап укыйм, рәсем ясыйм).**

**“Командир” уены**
**“Нишли? –Что делает?”**
*к проекту «Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар»* (диалог между воспитателем и детьми, между детьми).

**- Аша! Эч! Утыр! Бас! Сикер! Уйна! Йөгер! Ю! Йокла! Ки! Сал! Чана шу! Җырла! Бие! Китап укы! Рәсем яса!**

*Речевой образец:*
- Саша, утыр! *(Саша утыра).*
Саша нишли?
- Саша утыра.

**“Телефоннан сөйләшәбез” – “Разговариваем по телефону”.**

**Саша:** Алло.
**Оля:** Алло. Син кем?
**Саша:** Мин Саша.
**Оля:** Исәнме, Саша.
**Саша:** Хәерле көн, Оля. Хәлләр ничек?
**Оля:** Әйбәт. Рәхмәт. Саша, хәлләр ничек?
**Саша:** Әйбәт. Рәхмәт. Оля, Син нишлисең?
**Оля:** Мин алма ашыйм.
**Саша:** Нинди алма?
**Оля:** Тәмле алма. Ә син нишлисең?
**Саша:**Мин уйныйм.
**Оля:**Нәрсә белән?
**Саша:** Туп белән.
**Оля:** Туп нинди?
**Саша:** Туп матур, чиста, зур, кызыл. Оля, әни нишли?
**Оля:** Әни йоклый. Сау бул, Саша.
**Саша:** Сау бул, Оля.

# Лексик минимум

| №П/П | ЯШЬ АРАЛЫГЫ | АКТИВ (пассив) СҮЗЛӘР | СҮЗЛӘР САНЫ |
|---|---|---|---|
| 1. | 4-5 яшь | **Актив сүзләр:** әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш. (49 сүз)<br>**Пассив сүзләр:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз) | **62 сүз** |
| 2. | 5-6 яшь | **Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз)<br>**Пассив сүзләр:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз) | **45 сүз** |
| 3. | 6-7 яшь | **Актив сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр (58 сүз)<br>**Пассив сүзләр:** нәрсә яратасың? (2 сүз) | **60 сүз** |

# Милли региональ компонент

## *Уртанчылар төркеме*

| *Айлар* | *Тема* | *Максат* | *Эш төрләре* |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | *Безнең матур бакчабыз.* | Балалар бакчасы бинасы белән таныштыру. Төркем бүлмәсе буйлап экскурсия. Бер-берсе белән якыннан танышу,дуслашу. | Күзәтү, әңгәмә, экскурсия. |
| Октябрь | *Күңелле, кызык уйнавы бергә.* | Уен почмаклары белән танышу, уеннар өйрәнү. Уенчыкларга карата сакчыллык тәрбияләү. | Әңгәмә, сюжтлы уен “Кибет”. |
| Ноябрь | *Экологик сукмак буенча сәяхәт.* | Балалар бакчасы территориясе белән якыннан танышу. Урман почмагында табигать үзгәрешләрен күзәтү. | Экскурсия, үсемлекләр, кошларны күзәтү, хәрәкәтле уеннар. |
| Декабрь | *“Бәләкәч” - безнең матур бакчабыз.* | Балалар бакчасында эшләүче өлкәннәрнең һөнәрләре белән танышу (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, мөдир, шәфкать туташы һ.б.), һәр хезмәтнең мөһим булуын аңлату. | Экскурсия, әңгәмә, рәсемнәр карау, рәсем ясау. |
| Январь | *Баулы шәһәре буйлап сәяхәт.* | Балалар бакчасына якын мохит белән таныштыру. Хади Такташ урамы, Җиңү аллеясы буенча сәяхәт. | Экскурсия, әңгәмә, рәсемнәр карау, җырлар тыңлау. |
| Февраль | *Туган шәһәребез – Баулы.* | Балаларның гаилә, үзләре яшәгән мохит, күршеләр, урам һәм шәһәребез турындагы белемнәрен тулыландыру. | Әңгәмә, гаилә шәҗәрәләре төзү буенча башлангыч эш (ата-аналар катнашында), Баулы турында альбом төзү, җырлар, шигырьләр өйрәнү. |
| Март | *Тиздән әниләр бәйрәме.* | Өлкәннәргә ихтирамлы, игьтибарлы булу, ярдәмчеллек тәрбияләү. Милли киемнәр, татар халык ашлары белән танышу. | Күңел ачу кичәсе әзерләү, рәсемнәр ясау, әсәрләр уку. |
| Апрель | *Баулыга ямьле яз килде.* | Баулы ягы табигатенең матурлыгын күрү, хозурлана белү. Су буенда кара карга ояларын күзәтү. Яз турында әйтемнәр, мәкальләр өйрәнү. Табигатькә карата сакчыллык тәрбияләү. | Экскурсия, кара каргаларны күзәтү, фотога төшү, “Карга боткасы” бәйрәме оештыру. |
| Май | *Без майда туганбыз.* | Балаларның үз-үзләренә, иптәшләренә карата ихтирамлык тәрбияләү. Гаилә белән бердәм бәйрәмнәр оештыруның әһәмиятен аңлату. | Гаилә бәйрәме, туган көн бәрәме, рәсемнәр ясау. |

## *Өлкәннәр төркеме*

| *Айлар* | *I атна* | *II атна* | *III атна* | *IV атна* |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | “Туган шәһәрем – Баулы”. | “Бәләкәч” дип атала безнең матур бакчабыз. | Без яши торган урам. | Баулыбыз урамнары. |
| Октябрь | Табигать кочагында. | Үсемлекләр илендә. | Җәнлекләр дөньясы. | Баулы чишмәләре. |
| Ноябрь | Баулы тарихы битләре. | Баулының үсеше. | Баулыбызның бүгенге көне. | Без шәһәрдә яшибез. |
| Декабрь | Баулы нефть белән данлы. | Нефтьчеләргә һәйкәл. | Шәһәр транспорты. | Баулыбыз урамнары. |
| Январь | Без нефтьче булабыз. | Музейга экскурсия. | Бездә кунакта нефтьчеләр. | Хезмәт алдынгылары. |
| Февраль | Хезмәт кешесенә дан. | Ягез әле әниләр-әтиләр һөнәре. | Мин зур үскәч. | Халкыбыз җәүһәрләре. |
| Март | “Йөри безнең бакчага бик күп төрле балалар”. | “Уйныйбыз да, җырлыйбыз да”. | Халкыбызның милли бизәкләре. | Милли культура атналыгы. |
| Апрель | “Кошлар – безнең дуслар”. | Язгы бәйрәм “Карга боткасы”. | Онытылмас сугыш еллары. | Җиңү аллеясына экскурсия. |
| Май | Гаилә шәҗәрәсе. | Гаилә бәйрәме. | Иң матур ил – безнең ил! | Экологик сукмак буенча язгы сәяхәт. |

## *Мәктәпкә әзерлек төркеме*

| *Айлар* | *I атна* | *II атна* | *III атна* | *IV атна* |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | Иң матур ил – минем ил! | Нурлы Казан каласы. | Башкалабызга сәяхәт. | “Син Казанны беләсеңме?” – викторина. |
| Октябрь | Туган шәһәрем Баулы. | Районыбыз киңлекләре. | Татар авыллары. | Төрле милләт авыллары. |
| Ноябрь | Күпмилләтле гаилә. | Кадерле кыйммәтләр. | Милли киемнәр. Халык ашлары. | Безнең бәйрәмнәр. |
| Декабрь | Танылган шәхесләр. | Алтын каләм ияләре. | Ф.Яруллин иҗаты. | Р.Әхмәтҗанов, Р.Мостафин якташлары. |
| Январь | Халыкка моң өстәүчеләр. | Баулы көйләре. Г. Сайфуллин. | Гармун телләре. | Баулының мәдәният учаклары. |
| Февраль | Баулыбыз рәссамнары. | Музейга экскурсия. | Күңелле очрашулар. | Сәнгать мәктәбенә экскурсия. |
| Март | Үрнәк алабыз. | Әти-әниләребез һөнәрләре. | “Мәңгелек хәтирә”. | Җиңү аллеясына. |
| Апрель | Фольклор безнең тормышта. | Язгы бәйрәм “Карга боткасы”. | Халык җәүһәрләре. | Күңелле уеннар. |
| Май | Экологик сукмак буенча язгы сәяхәт. | Туган ягыбыз Баулы. | Гаилә шәҗәрәсе. | Безнең матур бакчабыз. |